МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_30.03.2019_ Казан ш. №_60-ОД_

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2016 елның 17 октябрендәге 272-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2016 елның 17 октябрендәге 272-ОД номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2018 елның 9 февралендәге 25-ОД, 2018 елның 14 июньдәге 142-ОД номеры боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

электр энергетикасы бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

кулланучылар базары хезмәте бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге бүлегенең әйдәп баручы консультанты.».

2. Җыелма бүлеккә (Л.М.Кадыйрова) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Ш. Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов